■ Сез беләсезме?

# ЗУР БҮЛӘК

**Җәүдәт хажи хәзрәт НИЯЗИ,**
**Ислам институты мөгаллиме**

*Әгүзү билләһи*
*минәшшайтаннир-ражим.*
*Бисмилләһир-Рахмәнир-Рахим.*
*Әлхәмдүлилләһи*
*Раббиль-галәмин.*

Аллаһы Раббыбыз мөселман халкына бүләк итеп җибәргән, күңелләрдә иман ялкыннары сыман балкыган нур биргән, Ислам диненә чын күңел белән ышанган халык өчен матур, бәрәкәтле тормыш төзергә өйрәткән вә Аллаһы Тәгаләнең берлегенә-барлыгына ышандырган һәм дә ике дөньяда да рухларга яктылык чыганагы белән юл күрсәтүче, вә Адәм балаларын туры һәм изге юлда алып баручы бөек хакыйкәтләр үзәге булган кадерле китабыбыз - Ќөрьән Кәрим турында сүзебез. "Бәкара" сүрәсенең 255нче аяте - сезнең игътибарыгызда булсын. Мөхәммәд пәйгамбәребез: "Әгәр дә кеше ошбу Аятел-Көрси догасын укый икән - ул адәм заты 70 ел Аллаһы Тәгаләгә хезмәт итүче булып исәпләнә һәм ул Раббыбызның зур бүләгенә ирешә", - дип әйтә.

Бу аять - Аятел-Көрси - адәм балаларына изге юл күрсәтә. Кешеләр аны юлга чыкканда һәм сәфәр вакытында укысалар, яки үзләре белән йөртсәләр, аларны бәләләрдән һәм афәтләрдән саклый, туры юл күрсәтә, адаштырмый.


Аятел-Көрси йортта була икән - йортны саклый, дошманнар кермәс өчен киртә куя; йорт һәм башка тораклар төзегән вакытта бу аят дүрт нигезгә куелса, йортка иман нуры, ямь керә, саулык-сәламәтлек була; мендәр астына куелса, ике кеше - хатын белән ир арасында мәхәббәт арта, теләгән гамәлләрне үтәргә ярдәм итә; балаларның мендәр-түшәкләре астында булса - аларны тыныч йоклата, саулык-сәламәтлек булдыра, шайтаннан саклый.

Чит кеше белән сөйләшкәндә Аятел-Көрси кесәңдә икән - сүзең өстен була. Ул шулай ук кимчелекне күрсәтми, гакыллы фикерләрдә йөретә.

Юлда йөрегән мөселман кардәшләр үзләренең автомобильләренә көзге кырыенда Аятел-Көрсине куялар, ул машина йөреткән кешене йоклатмый, үз бурычларын үтәргә ярдәм итә, туры юл күрсәтә, юл газапларыннан саклый.

Аятел-Көрси кешеләрне изге гамәлләр башкарырга чакыра; әгәр дә машина йөретүчеләр афәткә очраса, аны күргән чит кешеләр үзләренең ярдәмен күрсәтергә тырышалар һәм ярдәм итәләр.

Мөхәммәд пәйгамбәребез (с.г.с.): "Һәр кем Аятел-Көрсине намаз соңында даими укыса, үзе белән йөретсә, чын күңеле белән Аллаһының барлыгына-берлегенә ышанса, ул кешене үлемнән соң бер нәрсә дә Җәннәткә керүдән тыймас", - дигән, ягъни, ул кешеләрне вакытсыз үтермәс вә кыямәт көнендә урыны Җәннәттә булыр.



## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Йомадиәл ахыр-Рәҗәб 2012 миләди йыл**
**1433 һижри йыл.**

| Йомадиәл ахыр. Рәҗәб | Аҙна көндәре | Май, Июнь | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Дүшәмбе | 7 | 4.56 | 6.26 | 14.30 | 20.30 | 22.00 | 23.30 |
| 17 | Шишәмбе | 8 | 4.54 | 6.24 | 14.30 | 20.32 | 22.02 | 23.32 |
| 18 | Шаршамбы | 9 | 4.52 | 6.22 | 14.30 | 20.33 | 22.03 | 23.33 |
| 19 | Кесе йома | 10 | 4.50 | 6.20 | 14.30 | 20.35 | 22.05 | 23.35 |
| 20 | Йома | 11 | 4.48 | 6.18 | 14.30 | 20.37 | 22.07 | 23.37 |
| 21 | Шәмбе | 12 | 4.47 | 6.17 | 14.30 | 20.39 | 22.09 | 23.39 |
| 22 | Йәкшәмбе | 13 | 4.45 | 6.15 | 14.30 | 20.41 | 22.11 | 23.41 |
| 23 | Дүшәмбе | 14 | 4.43 | 6.13 | 14.30 | 20.42 | 22.12 | 23.42 |
| 24 | Шишәмбе | 15 | 4.41 | 6.11 | 14.30 | 20.44 | 22.14 | 23.44 |
| 25 | Шаршамбы | 16 | 4.40 | 6.10 | 14.30 | 20.46 | 22.16 | 23.46 |
| 26 | Кесе йома | 17 | 4.38 | 6.08 | 14.30 | 20.48 | 22.18 | 23.48 |
| 27 | Йома | 18 | 4.36 | 6.06 | 14.30 | 20.49 | 22.19 | 23.49 |
| 28 | Шәмбе | 19 | 4.35 | 6.05 | 14.30 | 20.51 | 22.21 | 23.51 |
| 29 | Йәкшәмбе | 20 | 4.33 | 6.03 | 14.30 | 20.53 | 22.23 | 23.53 |
| 30 | Дүшәмбе | 21 | 4.32 | 6.02 | 14.30 | 20.54 | 22.24 | 23.54 |
| 1 | Шишәмбе | 22 | 4.30 | 6.00 | 14.30 | 20.56 | 22.26 | 23.56 |
| 2 | Шаршамбы | 23 | 4.29 | 5.59 | 14.30 | 20.57 | 22.27 | 23.57 |
| 3 | Кесе йома | 24 | 4.27 | 5.57 | 14.30 | 20.59 | 22.29 | 23.59 |
| 4 | Йома | 25 | 4.26 | 5.56 | 14.30 | 21.00 | 22.30 | 00.00 |
| 5 | Шәмбе | 26 | 4.25 | 5.55 | 14.30 | 21.02 | 22.32 | 00.02 |
| 6 | Йәкшәмбе | 27 | 4.24 | 5.54 | 14.30 | 21.03 | 22.33 | 00.03 |
| 7 | Дүшәмбе | 28 | 4.22 | 5.52 | 14.30 | 21.05 | 22.35 | 00.05 |
| 8 | Шишәмбе | 29 | 4.21 | 5.51 | 14.30 | 21.06 | 22.36 | 00.06 |
| 9 | Шаршамбы | 30 | 4.20 | 5.50 | 14.30 | 21.07 | 22.37 | 00.07 |
| 10 | Кесе йома | 31 | 4.19 | 5.49 | 14.30 | 21.09 | 22.39 | 00.09 |
| 11 | Йома | 1 | 4.18 | 5.48 | 14.30 | 21.10 | 22.40 | 00.10 |
| 12 | Шәмбе | 2 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.11 | 22.41 | 00.11 |
| 13 | Йәкшәмбе | 3 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.12 | 22.42 | 00.12 |
| 14 | Дүшәмбе | 4 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.13 | 22.43 | 00.13 |
| 15 | Шишәмбе | 5 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.15 | 22.45 | 00.15 |

■ Тормыш рәвеше

# ИЗГЕ ЮЛДА БЕРДӘМЛЕК



**Венера КАРАМОВА,**
**Башкортостан республикасының атказанган укытучысы**
**Дүртөйле районы**

Иванай авылы - Дүртөйле районында иң зур, төзек матур авылларның берсе. Асфальт юллар, ике катлы күп фатирлы йортлар, урта мәктәп, ике катлы зур мәдәният йорты һ.б. әллә кайдан кешеләрне үзенә тартып торалар. Әйе, бу төзелешләр совет чорында Социалистик Хезмәт Герое Рифкать Салих улы Еникеев Карл Маркс исемендәге колхоз белән рәислек иткән вакыттан калган истәлекле биналар. Рифкать Салих улының урыны Җәннәттә булсын, хуҗалык хәзер инде аның исемен йөртә.

Иванай авылының мәдәният сарае янында моннан 15 ел элек мәчетебез төзелү барлык халык өчен дә зур шатлык булды. Аны колхозыбызның иң уңган балта осталары, төзүчеләр бик зәвык, милли бизәкләр белән бизәп тырышып төзеделәр. Хезмәт һәм сугыш ветераннарының. авыл халкының үтенечен колхоз рәисе Ирек Камалов, Тәкәрлек авыл советы рәисе Шамил Хәсәнов бик җитди карадылар һәм бу эшкә иң яхшы төзүчеләрне беркеттеләр. Рәшит Мостафин мәчетне төзекләндерү өчен зур тырышлык күрсәтте. Хәер, ярдәм итүчеләр күп булды.

Мәчетнең беренче имам-хатибы Фәзнәви Әфләтүнов сигез ел дәвамендә бик яхшы эшләр эшләде. Гарәп әлифбасы өйрәтү, дини бәйрәмнәр үткәрү һ.б. Аннан соң бу эшне хажи Әхмәтзаһит Кәлимуллин дәвам итте. Бездә дини бәйрәмнәр, дин дәресләре зур оешканлык белән үтә. Ноябрь аеннан апрель уртасына кадәр шәкертләр дин сабаклары алдылар, әлхәмдулиллаһ! Яшьләрнең никахлашу бәйрәмнәре, бәбәйләргә исем кушу йолалары да бик матур, шәригать кушканча үтә.

Авыл кешеләре сөенеп бетә алмый: күпме яшьләр ата-баба юлында - иманга кайталар. Мәчет төзелүенет 15 еллыгын Мәүлид бәйрәме белән бергә туры китереп бәйрәм итүебез бер дә юкка түгел. Пәйгәмбәребез Мөхәммәт (с.г.с.) туган айда аңа салаватлар әйтеп, Аллаһка үзебезнең рәхмәтебезне җиткердек. Имам-хатибыбыз Әхмәтзаһит хажи вәгазь сөй-ләде. Хажия Фәһирә Әхмәтова, шулай ук Альбина Камгалова, Мәбрүрә Сәлимова, Люция Хакимова абыстайларның эчтәлекле сөйләүләрен халык зур игътибар белән тыңлады. Бәйрәмнең икенче өлешендә мәчет төзүдә башлап йөрүчеләрне искә алып, Әхнәф Ахунов, Рәис Сабиров рухына догалар кылдык.

Мәчетебез 1996 елның 27 декабрендә ачылды. 15 ел сизелми дә үткән, бу елларда күпме кеше Аллаһ йортында гыйлем алды, намаз укып, тәүбә итте!

Әхмәтзаһит хажи аерым кешеләргә рәхмәтен җиткерде. Фәһим Исмәгыйлов, Фәнәви Исхаков, Әмирьян Сәлимханов, Мөхәммәтзадә Сәхипзадин, шулай ук Үзбәк Гимаев, Фәнәви Галимҗанов, Рәшит Дәүләтов, Ирек Камалов, Альфред Әхмәтов - мәхәллә советының иң актив әгъзалары да. Абыстайларыбыз да алардан калышмыйлар: Нәҗибә Касыймова, Мәврүрә Сәлимова, Сәкинә Шәрәфетдинова, Рәзинә Әхмәтова, Галия Гыйззәтуллина, Сания Мөхәммәтдинова һ.б. һәр эштә дә активлар. Аллаһ йортын һәрвакыт матур да, төзек тә, чиста да тотуда ярдәм итүчеләрне исемләгәннән соң, хажи юбилярларны да туган көннәре белән котлады. Мәчетнең аксакаллары Әмирьян Сәлимхановка, Фәнәви Галимжановка һәм абыстаебыз Зөһрә Галәветдиновага 80 яшь тулды. Аларга истәлекле бүләкләр тапшырылды. Бәйрәмчә олы табынны "Таң" җәмгыяте әзерләгән иде. "Тулпар" кибете хуҗасы Илшат Гимаев та буш кул белән килмәде.

Имам-хатипка кушылып, колхозның ветераннар советы рәисе Нурхәниф Мифтәхетдинов киң күңелле кешеләргә үзенең олы рәхмәтен җиткерде.

Бүген дә Иванай мәчетендә иман дәресләре өйрәнү, укулар бара. Фәһирә Әхмәтова 7 ел инде шушы изге эштә үзенең көчен сала. Абыстай эчтәлекле дәресләрендә теория белән практиканы бергә алып бара, әхлакәдәплелек минутлары да бар, тәҗвид фәне белән дөрес матур язу, дөрес укуда таләпчәнлек зур.

Балалар төркемен икенче ел инде Галия-Фәһирә Гыйззәтуллина укыта. Әйе, көн дә мәчетебез ачык. Олысы да, кечесе дә әле сорау белән, әле киңәш белән киләләр. Аллаһ йортына халык йөри, киләсе уку елына 1нче сыйныфка теләүчеләр языла да башлады. Әлхәмдүлиллаһ, мәчетнең киләчәге өметле.

■ Хикәят

# Шәкерткә яхшылык итүнең файдасы

Көннәрдән бер көнне Хәсән Бәсрый (Аллаһның рәхмәте төшкере!) болынга чыкты. Бер олы су читендә тукталып, карап тора иде. Күрде: бер бака, бер чаянны аркасына мендереп, каядыр бара. Хәсән Бәсрый карап торды да: "Чаян кая барыр икән?" - дип, артыннан китте.

Чаян бер агач төбенә килде. Ул агач төбендә бер кеше йоклап ята иде. Агачның башында кош оясы бар икән. Кош оясына бер олы елан менеп, чагып һәлак итәм дигән вакытта, чаян кара еланның үзен чагып үтерде.

Хәсән йоклаган кешене уятты. Кеше торды, тирә-ягына каранды, әйтте:

- Күп йоклаганмын икән, - диде. Күзе кара еланга төште, гаҗәпләнде: - Моны кем үтерде? Юкса мине чагып һәлак итәр иде, - дип сорады.

Хәсән:

- Бүген син бик яхшы эш эшләгәнсәң, ахры, - диде.

Ул кеше әйтте:

- Һич гомеремдә харам вә бозык эштән гайре эш эшләгәнем юк иде. Мәгәр бу көн гыйлем өйрәнүче бер шәкерткә очрадым. Тамагы ач икән, бик үтенеп, миннән ашарга сорады. Минем бер көмәчем бар иде, аны бирдем. Мәгәр бар изгелегем шулдыр, - диде.

* * *

Шулай итеп, мәгълүм булды: бер шәкерткә бер көмәч биргәнгә күрә, хак Тәгалә елан бәләсеннән саклады. Ахыр дөньяда тәмуг газабыннан да сакласа, һич гаҗәп булмас. Шәкерткә яхшылык итү шулкадәр изге икән.

# Бала күңелен күрүнең хакы

Шәһәрдә бер явыз кеше бар иде. Һәртөрле начарлык, бозыклыкны шул явыз эшләде. Тәмам гомерен шул рәвешчә кичерде.

Аның ишегалдында бер олы агачбар иде, бу явызга Аллаһы Тәгаләдән каһәр килгәнен күреп, ул агач куркып корыды. Бу явызның шомлыгыннан хәтта ул җирдә үлән үсмәс иде.

Көннәрдән бер көнне бу явыз үзенең бозыклык белән шөгыльләнүеннән кайтып килә иде, елап торучы бер кечкенә балага рәхиме килеп, корыган агачтан бер чыбык сындырып алып бирде, баланы елавыннан юатты, күңелен күрде.

Хак Тәгалә, баланы юатып, күңелен күргәне өчен, бу явызның бар гонаһларын гафу итеп, үзенең дусларыннан кылды. Агачта бу хәлне күреп сөенде, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән яшәрде, янә яфраклары яшелләнде.

* * *

Шулай итеп, мәгълүм булды: сабый балаларның күңелен күреп юатканга, Хак Тәгаләнең олы рәхмәте, гафу итүчәнлеге бар икән.

